**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

« 8 » июня 2020 | с. Тюлячи | № 250

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә төркемнәрне кыскарту турында

МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» начальнигының 2020 елның 29 маендагы 161 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон нигезендә, бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Айдар авылы балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә 2020 елның 1 сентябреннән «кече тәрбияче» 0,5 штат берәмлеген һәм «каравылчы» 0,5 штат берәмлеген кыскартырга.

2. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.), МКУ «Теләче муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» (Павлова Л.П.), әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә гамәлдәге законнар нигезендә эштән азат ителгән хезмәткәрләргә гарантия һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче | Н.Н. Хаҗипов